ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

18.03.2024 ел. № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башлыгының 2024 елның 7 мартындагы №1 карары “ Татарстан Республикасы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында “Татарстан Республикасы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы 2023 елның 07 декабрендәге 1 номерлы, “2024 елда ”Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнарның үзара салымын билгеләү турында”гы 2023 елның 07 декабрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Татарстан Республикасы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктындагы гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башлыгының 2024 елның 7 мартындагы №1 карары “ Татарстан Республикасы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында “Татарстан Республикасы Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы 2023 елның 07 декабрендәге 1 номерлы, “2024 елда ”Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пунктында гражданнарның үзара салымын билгеләү турында”гы 2023 елның 07 декабрендәге 2 номерлы карарларына гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны бәян итеп, түбәндәге редакциядә:

Сез, 2024 елда Сарлы авыл җирлегенең Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 1,2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, мобилизацияләнгән гражданнарда һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгәннәрдән 250 сум күләмендә, үзара салым алуны кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлтергә:

- Сарлы торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (урамнарны яктырту лампаларын һәм запас частьләрне (фотореле, клипслар, чыбыклар һәм башка кирәкле комплект детальләрен) сатып алу, урам яктырту лампаларын алыштыру буенча электр хезмәтләре өчен түләү);

- Сарлы торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәте өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- Сарлы торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарлы авылы территориясен яшелләндерү чаралары, үләнне механикалаштырылган чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Сарлы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторчының карын

механикалаштырылган җыештыру буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу хезмәтләре);

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Сарлы торак пунктында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен агымдагы ремонтлау, буяу һәм төзелеш материаллары сатып алу);

- Сарлы торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, традицион рәвештә күмү урыннарын төзекләндерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, традицион каберлекләр урынында каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, Сарлы авылындагы зиратына коймага материаллар сатып алу)»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда 300 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 172 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" - 172 катнашучысы тавыш бирде, "КАРШЫ" - 0 катнашучы тавыш бирде.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Азнакай муниципаль районының
халык җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлегенең Башлыгы _______________ И.М. Камалетдинов
(имза)